ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02 2019 ЕЛ Болгар шәһәре № 66

Спас муниципаль районында 2003-2004 елда туган егетләрне хәрби хезмәткә әзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турында Нигезләмәне раслау хакында" 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карары, Россия Федерациясе Оборона министрының «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында» 2001 елның 23 маендагы 240/168 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Спас муниципаль районы буенча 2003-2004 елларда туган егетләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча 2019 елга дәвалау-сәламәтләндерү чаралары планын (1 нче кушымта) расларга.
2. 2003-2004 елларда туган яшүсмерләргә профилактик тикшерүләрне үткәрү буенча медицина комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).
3. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның баш табибы Е.И. Самохвалов белән килешү буенча:

3.1.2019 елның 13 апреленнән 20 апреленә кадәр район территориясендә яшәүче һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы 2003-2004 елларда туган яшүсмерләргә планлы профилактик медицина тикшерүләрен үткәрергә.

3.2.яшүсмерләргә профилактик медицина тикшерүе үткәрүне кирәкле медицина җиһазлары һәм инструментлар белән тәэмин итәргә.

3.3. профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү алдыннан флюорография һәм лаборатория тикшеренүләре үткәрергә. Билгеләнгән эш һәм отчет документларын вакытында рәсмиләштерүне тәэмин итәргә.

3.4. профилактик тикшерүләрнең нәтиҗәләре турында мәгълүматларны әзерләргә һәм бирергә.

4. "Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МУ җитәкчесе А. Н. Ермилинга карау барган көннәрдә укучыларны дәресләрдән азат итәргә.

5. Авыл җирлекләре башлыкларына «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУгә график нигезендә яшүсмерләр килүен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. 3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Афоньшинага йөкләргә.

Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
1нче кушымта
№66 01.02. 2019 ел.

Спас муниципаль районы буенча 2003-2004 елларда туган егетләрне
хәрби хезмәткә әзерләү буенча
2019 елга дәвалау-сәламәтләндерү чаралары планы

| № | Чаралар | Башкару срогы | Башкаручылар | Башкару турында билге |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Хәрби учетка куелганчы, медицина каравы узарга тиеш яшүсмерләрнең исемлеген төзү. | 05.02.2019 елга кадәр. | 1.Гомумбелем бирү учрежениеләре шәфкать туташлары.<br>2. ФАП фельдшерлары.<br>3.Җирле үзидарә органнары.<br>4.Участок шәфкать туташлары. | |
| 2 | 15-16 яшьлек егетләргә профилактика медицина тикшерүе үткәрүнең план-графигын төзү. | 04.03.2019 елга кадәр. | 1. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның район педиатры.<br>2. «Спас муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МУ. | |
| 3 | Лабооратория тикшеренүләренең план-графигын төзү. | 04.03.2019 елга кадәр. | 1. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның балалар консультациясе. | |
| 4 | График нигезендә, диспансеризация үтәргә тиешле егетләрнең лаборатория тикшеренүләрен үткәрү (кан, сидек анализлары, флюорография, ЭКГ) | 13.04.19 елдан 21.04.19 елга кадәр. | «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның лаборатория-диагностика бүлеге. | |
| 5 | Һәр егеткә тиешле документларны тутыру. | до 03.04.16 г. | 1. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның балалар консультациясе. | |
| 6 | Ф – 25-Ю формаларында анализлар, амбулатория карталарыннан өземтәләр булуны тәэмин итү. | 04.04.19 елга кадәр. | 1. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның балалар консультациясе. | |
| 7 | РФ Оборона министрлыгы һәм Сәламәтлек саклау министрлыгының 23.05.2001 елгы «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында» №240-168 бердәм боерыгында күздә тотылган күләмдә 15-16 яшьлек егетләргә медицина тикшерүе үткәрү. | 13.04.19 елдан 20.04.19 елга кадәр. | Медицина комиссиясе әгъзалары. | |
| 8 | Медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында аналитик белешмәне (мәгълүматны) хәрби комиссариатка житкерү (240-168 боерыгының 4нче кушымтасы) | 13.05.19 елга кадәр. | «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **9** | Егетләргә профилактик медицина тикшерүе үткәрүгә йомгак ясау һәм дәвалау-савыктыру чаралары планын төзү. | 25.05.19 елга кадәр. | 1. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибының поликлиника буенча урынбасары.<br>2.Район педиатры. | |
| **10** | График нигезендә, поликлиника, район үзәк хастаханәсе стационарында, кирәге чыккан очракта, республика клиник хастаханәсендә дәвалау-савыктыру чаралары уздыру. | 03.06.19 елдан 04.11.19 елга кадәр. | 1.Педиатр.<br>2. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУның табиб-белгечләре. | |
| **11** | Дәвалау-профилактика чараларын вакытында, тулы күләмдә һәм сыйфатлы итеп уздыруны контрольдә тоту. | ай саен | 1.Район педиатры.<br>2. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибының поликлиника буенча урынбасары. | |
| **12** | Егетләрне хәрби учетка куйганчы медицина ярдәме белән тәэмин итү нәтиҗәләрен тикшерү буенча медицина советларын үткәрү. | ноябрь 2019 ел | 1.Район педиатры.<br>2. «Спас үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибының поликлиника буенча урынбасары. | |

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2нче кушымта
№ 66 01.02.2019 ел.

**Медицина комиссиясе составы:**

1. Ермилова Л.В. район педиатры, комиссия рәисе
2. Габдрәшитов И.Н. табиб-стоматолог
3. Гриненко Д.Р. табиб-отоларинголог
4. Доолбек уулу Медербек. табиб-невролог
5. Кәбиров Р.З. – табиб-травматолог
6. Камалова Л.В. табиб-окулист